Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы
Кармалка авыл җирлегенең
Кармалка торак пункты гражданнар җыены
КАРАРЫ

2023 елның 19 ноябре № 1

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Кармалка авыл җирлегенең Кармалка торак пункты гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 19 ноябрендә узган «Сез 2024 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Кармалка авыл җирлеге Кармалка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 85 яшьтән өлкәнрәкләр һәм балалары махсус хәрби операциядә катнашучы һәм һәлак булганнарның ата-аналардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә билгеләү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм җирләү урыннарын тоту:

зиратны киңәйтү

Торак пункт чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, су чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру:

- сууткәргечне ремонтлау

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 130 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 80.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 80 кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Кармалка авыл җирлегенең Кармалка торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Кармалка авыл җирлеге составына керүче Кармалка торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. «Сез 2024 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Кармалка авыл җирлеге Кармалка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 85 яшьтән өлкәнрәкләр һәм балалары махсус хәрби операциядә катнашучы һәм һәлак булган ата-аналардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә билгеләү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм җирләү урыннарын тоту:

зиратны киңәйтү

Торак пункт чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, су чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру:

- суүткәргечне ремонтлау

«РИЗА» «КАРШЫ»сораулары буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Мордва Кармалка авылы, Геодезия ур., 38 а йорт, 2 корылма (административ бина), Нагорный ур., 33 йорт (авыл мәдәният йорты) адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
«Кармалка авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы О.В.Кириллова